РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.12.2018 № 1887-п

Архив эше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1.1. Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

1.2. Бетерелә торган оешмаларның шәхси составы буенча муниципаль архивка саклауга документлар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

1.3. Юридик затларга архивлар эшендә методик һәм практик ярдәм күрсәтү һәм эш башкаруда документлар оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

1.4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлегендә саклана торган архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив фондлары буенча архив документларының күчермәләрен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

1.5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлегендә сакланган архив документларын уку залында эшләү өчен кулланучыга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.

1.6. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлегендә саклаган һәм дәүләт милкенә кертелгән архив документларын уку залында эшләү өчен кулланучыга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты;

1.7. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлегендә саклаган һәм дәүләт милкенә караган архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив фондлары буенча архив документларының күчермәләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты;

1.8. Дәүләт милкенә караган архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты;

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

– «Архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 06 маендагы 565-п номерлы карары;

– «Архив өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 16 сентябрендәге 1155-п номерлы карарының 1 пунктын;

– «Архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 12 августындагы 1020-п номерлы карары.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге башлыгы А.Н. Сиражетдиновага йөкләргә.

Саба муниципаль районының
Башкарма комитеты
Җитәкчесе М.Р. Ишниязов